**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об особенностях командирования лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, государственных гражданских служащих Республики Татарстан, работников государственных органов Республики Татарстан, замещающих должности, не являющиеся должностями государственной гражданской службы Республики Татарстан, на территории Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики, Запорожской области и Херсонской области

В целях повышения уровня социальной защищенности лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан, государственных гражданских служащих Республики Татарстан, работников государственных органов Республики Татарстан, замещающих должности, не являющиеся должностями государственной гражданской службы Республики Татарстан, **постановляю:**

1. Установить, что лицам, замещающим государственные должности Республики Татарстан, государственным гражданским служащим Республики Татарстан, работникам государственных органов Республики Татарстан, замещающим должности, не являющиеся должностями государственной гражданской службы Республики Татарстан, в период их нахождения в служебных командировках на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики, Запорожской области и Херсонской области:

а) денежное вознаграждение (денежное содержание) выплачивается в двойном размере;

б) дополнительные расходы, связанные с проживанием вне постоянного места жительства (суточные), возмещаются в размере 8 480 рублей за каждый день нахождения в служебной командировке;

в) государственные органы Республики Татарстан могут выплачивать безотчетные суммы в целях возмещения дополнительных расходов, связанных с такими командировками.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан:

а) обеспечить для работников организаций и учреждений, подведомственных государственным органам Республики Татарстан, принимающих непосредственное участие в выполнении работ (оказании

услуг) по обеспечению жизнедеятельности населения и (или) восстановлению объектов инфраструктуры (в том числе по восстановлению вооружения, военной и специальной техники) на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики, Запорожской области и Херсонской области, установление условий командирования, аналогичных условиям, предусмотренным настоящим Указом;

б) в 14-дневный срок привести свои акты в соответствие с настоящим Указом.

3. Финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа, осуществлять за счет средств, предусматриваемых в бюджете Республики Татарстан соответствующим государственным органам Республики Татарстан.

4. Внести в Положение о порядке и условиях командирования государственных гражданских служащих Республики Татарстан, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 9 сентября 2005 года № УП-366 «О порядке и условиях командирования государственных гражданских служащих Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 11 января 2008 года № УП-3, от 12 июля 2010 года № УП-445, от 14 октября 2010 года № УП-695, от 17 ноября 2010 года № УП-751, от 14 февраля 2011 года № УП-57, от 5 октября 2011 года № УП-627, от 18 января 2013 года № УП-31, от 12 февраля 2013 года № УП-108, от 25 февраля 2015 года № УП-189, от 19 октября 2015 года № УП-998 и от 25 декабря 2017 года № УП-1157), изменение, дополнив пункт 16 словами «, если иное не предусмотрено указом Президента Республики Татарстан».

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания и распространяется на правоотношения, возникшие с 30 сентября 2022 года.

**Президент Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
24 декабря 2022 года
№ УП-920

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы булмаган вазыйфаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләрен Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләренә командировкага җибәрү үзенчәлекләре турында

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы булмаган вазыйфаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренең социаль якланганлыгы дәрәҗәсен арттыру максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы булмаган вазыйфаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренә Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә хезмәт командировкасында булу чорына түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) акчалата түләү (хезмәт хакы) икеләтә күләмдә түләнә;

б) даими яшәү урыныннан читтә яшәүгә бәйле өстәмә чыгымнар (көнлек түләүләр) хезмәт командировкасының һәр көне өчен 8 480 сум күләмендә кайтарып бирелә;

в) мондый командировкаларга бәйле өстәмә чыгымнарны кайтарып бирү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт органнары хисапка алынмый торган акча түләргә мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

а) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә яшәүчеләрнең яшәешен һәм эшчәнлеген тәэмин итү һәм (яки) инфраструктура объектларын торгызу (шул исәптән коралны, хәрби һәм махсус техниканы торгызу буенча) буенча эшләр башкаруда (хезмәтләр күрсәтүдә) турыдан-туры

катнашучы дәүләт органнары карамагындагы оешмалар һәм учреждениеләр хезмәткәрләре өчен командировка шартларын бу Указда күздә тотылган шартларга тәңгәл итеп билгеләүне тәэмин итәргә;

б) 14 көн эчендә үзләренең актларын бу Указга туры китерергә.

3. Әлеге Указны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны Татарстан Республикасы бюджетында тиешле дәүләт органнарына каралган акча хисабыннан башкарырга.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында» 2005 елның 9 сентябрендәге ПУ-366 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 11 гыйнварындагы ПУ-3 номерлы, 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 14 октябрендәге ПУ-695 номерлы, 2010 елның 17 ноябрендәге ПУ-751 номерлы, 2011 елның 14 февралендәге ПУ-57 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-627 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы, 2013 елның 12 февралендәге ПУ-108 номерлы, 2015 елның 25 февралендәге ПУ-189 номерлы, 2015 елның 19 октябрендәге ПУ-998 номерлы һәм 2017 елның 25 декабрендәге ПУ-1157 номерлы Указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары нигезләмәсенә, 16 пунктка «, Татарстан Республикасы Президенты указында башкасы күздә тотылмаган булса,» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 30 сентябреннән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 24 декабрь
№ ПУ-920